ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШЛАНГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Улица Колхозная, дом 1,
село Шланга, 422474
ИНН 1617003275

Колхоз урамы, 1нче йорт,
Шланга авылы, 422474

Тел.: (84375) 3-91-36, 8(9377754063), факс: (84375) 3-91-36, e-mail: Shlang.Drz@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 январь 2021 ел № 3

Шланга авыл җирлеге территориясендә стационар
булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү
хокукына рөхсәт бирү" муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Башкарма комитетының 13.03.2017 ел, №3 карары белән (25.05.202020 ел, № 6 редакциясендә) расланган "Шланга авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру һәм эксплуатацияләү хокукына рөхсәт бирү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**Түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:**

“2.6.2. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, шулай ук мөрәҗәгать итүче аларны, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә әлеге документлар белән эш итүче оешма карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге:

1) Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар);

2) Үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә килеп чыккан, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә, (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).

Мөрәҗәгать итүченең документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.6 пункты белән билгеләнгән";

**2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:**

" Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу турында мәгълүмәт .";

**3.3 пунктның 2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

"салымнар, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.".

2.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталын урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Шланга авыл җирлеге башлыгы: И.И.Якупов